КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 октябрь г.Казань № 799

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт биремен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт биремен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт биреме үтәлешен финанс белән тәэмин итү нәтиҗәлелеген арттыру, Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт биремен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 8 апрель, 205 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче; 2019 ел, 25 июнь, 513 нче; 2023 ел, 29 сентябрь, 1203 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт биремен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Дәүләт биреме үтәлешен башкаруны финанс белән тәэмин итү күләме дәүләт учреждениесенә беркетелгән яки түбәндәге мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен сатып алу өчен дәүләт учреждениесенә гамәлгә куючы тарафыннан

бүлеп бирелгән акча исәбеннән аның тарафыннан сатып алынган күчемсез мөлкәтне һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне (арендага бирелгән яки түләүсез файдалануга тапшырылган мөлкәттән тыш) (алга таба – учреждение мөлкәте) карап тотуга чыгымнарны исәпкә алып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар, эшләр башкаруга бәйле норматив чыгымнар нигезендә исәпләнә.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Дәүләт биреме үтәлешен финанс белән тәэмин итү күләме (R) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R = \sum_i N_i \times V_i + \sum_w N_w \times V_w - \sum_i P_i \times V_i - \sum_w P_w \times V_w,$$

монда:

$N_i$ – дәүләт биреме белән билгеләнгән i дәүләт хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар;

$V_i$ – дәүләт биреме белән билгеләнгән i дәүләт хезмәте күләме;

$N_w$ – дәүләт биреме белән билгеләнгән w эш башкаруга норматив чыгымнар;

$V_w$ – дәүләт биреме белән билгеләнгән w дәүләт эше күләме;

$P_i$ – әлеге Нигезләмәнең 28 пункты нигезендә i дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт биреме белән билгеләнгән түләү күләме (тариф, бәя);

$P_w$ – әлеге Нигезләмәнең 28 пункты нигезендә w дәүләт эшен башкарган өчен дәүләт биреме белән билгеләнгән түләү күләме (тариф, бәя).»;

27 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34. Учреждение тарафыннан ирештерелгән дәүләт биреме үтәлмәгән очракта, дәүләт биремен финанс белән тәэмин итү күләме ($R_n$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R_n = \sum_i N_i \times V_{i1} + \sum_i N_{i2} \times V_{i2} + \sum_w N_w \times V_{w1} - \sum_i P_i \times V_{i1} - \sum_w P_w \times V_{w1},$$

монда:

$V_{i1}$ – хисап чоры йомгаклары буенча дәүләт биреме белән билгеләнгән i дәүләт хезмәтенең факттагы күләме;

$N_{i2}$ – дәүләт биреме белән билгеләнгән i дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив чыгымнар составында дәүләт хезмәте күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗлары чыгымнары;

$V_{i2}$ – дәүләт биреме белән билгеләнгән i дәүләт хезмәтенең планлаштырылган күләменең хисап чоры йомгаклары буенча i дәүләт хезмәтенең фактик күләменнән тайпылышы;

$V_{w1}$ – хисап чоры йомгаклары буенча дәүләт биреме белән билгеләнгән w дәүләт эшенең факттагы күләме.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин